Л.М.Габдулла

# МӘСИХ

КАЗАН
ИЗГЕ ХӘБӘР
2001

# Әхмәт һәм Хәмит

Әхмәт бер оешмага эшкә ялланды. Ул үз эшеннән канәгать түгел дип әйтсәк, бу бөтенләй үк дөрес булып бетмәс иде. Әмма аңа җитәкчесе белән эшләргә авыр иде, чөнки ул бела торып, Әхмәткә үзенең бар сәләтен күрсәтергә мөмкинчелек бирми иде. Аларның бүлекләре берәр төрле катлаулырак эш башкарса, бар данны җитәкчесе үзенә ала иде.

Әхмәт инде берничә тапкыр эшен алыштырырга да уйлап карады. Әмма ул вакытта яхшырак эш табуы бик җиңел түгел иде. Өстәвенә Әхмәтнең хезмәт хакы, башка урыннарда тәкъдим иткәнгә караганда, күпкә югарырак иде. Шуңа күрә Әхмәт һаман да бу эшендә кала бирде. Чөнки аңа хатынын һәм өч баласын тәэмин итәргә акча кирәк иде. Әхмәт балалары, бигрәк тә институтта икътисадчыга укучы өлкән улы Хәсән белән бик горурлана иде.

Көннәрдән бер көнне аларның бүлегендә бер хәл булды, һәм барысы да яхшы якка үзгәрде. Аларның бүлегенә Хәмит исемле кеше эшкә урнашты. Ул Әхмәттән бераз яшьрәк, шат күңелле, ачык чырайлы кеше иде. Шуңа күрә аның белән эшләве дә җиңел иде. Ниһаять, Әхмәткә дә эшендә дус табылды! Алар бергә төшке ашка йөрделәр, һәм эштән соң да очраша башладылар. Хәмит тә өйләнгән кеше иде. Аллаһы Тәгалә аңа дүрт бала - ике малай һәм ике кыз бүләк иткән иде.

Бик тиздән Хәмит һәм Әхмәт иң якын дусларга әверелделәр, бер-берсенә кунакка да йөрешә башладылар. Аларга бер-берсендә чәй эчеп, сөйләшеп утыру бик ошый иде! Алар бер-берсе белән сөйләшә-сөйләшә вакытның үткәнен сизми дә калалар иде.

Баштарак алар эшләре турында, әмма вакыт үтү белән, тормышның мөһим сораулары турында да фикер алыша башладылар. Алар икесе дә дингә бик җитди карыйлар иде, ләкин алар икесе ике дингә ышаналар иде. Әхмәт - мөселман, ә аның иң якын дусты Хәмит Биб-

лияне көн саен укый һәм Мәсих Гайсәнең өммәте иде (Мәсих - Алла тарафыннан дөньяны коткару өчен сайланып май сөртелгән Зат дигән сүз).

Чынлыкта исә Әхмәтне шул гаҗәпләндерә иде - ул Хәмитне күбрәк белгән саен, аның иманын һәм Аллаһыга багышлаган тормышын күбрәк хөрмәт итә башлады. Әхмәт дустының Аллаһы белән нинди якын мөнәсәбәттә икәнлеген аңлый башлады. Ул үзе исә бу турыда хәтта чамалый да алмый иде, шуңа күрә бу аны бик кызыксындырды. Әхмәт шунда, Хәмитнең Аллаһыга багышланган тормышы һичшиксез нәкъ Мәсих белән бәйләнгән, дигән нәтиҗәгә килде. Билгеле бер мәгънәдә Әхмәт шулай ук Мәсихкә ышана, ләкин бу ничектер башкача иде. Ул Мәрьям улы Гайсә турында Коръәндә язылганнарның барсына да ышана иде. Ул Мәсихне бик хөрмәт итә иде. Әхмәт Мәсихне Мәрьям Кыз тудырганлыгын, Аның Алла ризалыгы белән бик күп могҗизалар булдыруын һәм Алладан Инҗилне кабул итүен белә иде инде. Шул ук вакытта ул үзенең Мәсих тормышыннан бары тик кайбер нәрсәләрне генә белүен аңлый иде. Шуңа күрә бу бөек Аллаһы рәсүле турында (Аңа хәтта Коръәндә дә бик күп исемнәр бирелгән!) ул тагын да күбрәк белергә тели иде.

Һиһаять, көннәрдән бер көнне Әхмәт үзенең иң якын дусты Хәмиттән Мәсих турында сорарга булды. Аның бу карары алар арасында күп кенә кызыклы әңгәмәләр барлыкка килүгә сәбәп булды.

## Аллаһы Бәрәне

- Миңа Мәрьям улы Гайсә турында сөйлә әле, - дип үтенде Әхмәт. - Минем Аның турында күбрәк беләсем килә.

Хәмит азрак уйланып торганнан соң, болай диде:

- Әгәр Мәсихнең бу дөньяга нигә килүен аңларга теләсәң, сиңа корбанның мәгънәсен аңларга кирәк.

- Корбан? Син нәрсәне күздә тотасың? - дип сорады Әхмәт.

Хәмит болай җавап бирде:

- Без корбанның мәгънәсен корбан бәйрәме мисалында аңлыйбыз. Син беләсең бит, Аллаһы Ибраһимнан үз улын корбан итеп бирүен сораган вакыттан соң, бу вакыйга билгеләп үтелә. Әгәр Аллаһы корбанны, аның өчен йолым итеп бирмәгән булса, Ибраһимның улы белән нәрсә булыр иде?

- Исмәгыйль вафат булыр иде, - диде Әхмәт.

- Корбанның мәгънәсе менә шуннан гыйбарәт тә инде, - диде Хәмит. - Кемдер берәү башка берәү өчен һәлак була. Аллаһы аның урынына корбан итү өчен, тәкә җибәргән. Минем хәлем дә Ибраһимның улыныкы кебек. Минем өстемнән үлем хакимлек итә.

- Син моның белән нәрсә әйтергә телисең? - дип сорады Әхмәт, бераз уңайсызланып. Хәмит бик җитди итеп җавап бирде:

- Изге Язмада (Библиядә) болай язылган:

***«Гөнаһ өчен әҗер - үлем» (1)***

Минем гөнаһым өчен җәза - үлем. Мин гөнаһлы. Әйе, дөрес, кешеләр алдында мин бик тәкъва кебек. Мин көн саен дога кылам, Аллаһы Сүзен укыйм, Аңа хезмәт итәм. Ләкин Аллаһы алдында мин гөнаһлы. Аллаһы каршында камил булган бер генә кеше булса да бармы? - дип сорады Хәмит.

- Юк, бары тик бер Аллаһы кына камил! - дип җавап бирде Хәмит.

- Димәк, Аллаһы алдында барысы да гөнаһлы, дөресме? - дип сорады шунда Хәмит.

- Әйе, әлбәттә, - дип ризалышты Әхмәт.

- Шулай булгач, минем хәлем дә Ибраһим улыныкы кебек - үлем каһәре астында. Әмма минем гөнаһым өчен корбан кайда соң? Бәлки, Аллаһы корбанны йолу буларак минем өчен җибәргәндер? - дип соравын дәвам итте Хәмит.

Әхмәт нәрсә әйтергә дә белмәде. Хәмит дәвам итте:

- Мәсих белән бер вакытта яшәгән Зәкәрия улы Яхъя, Аны беренче күрүгә үк болай дигән:

***«Менә (Үзенә) дөньяның гөнаһын алучы Алла Бәрәне!» (2)***

Мәсих кеше бәрәне булмаган. Ул Аллаһы Бәрәне булган. Ул Аллаһы яныннан килгән. Ул югарыдан килгән. Аллаһы Рухы Мәрьям Кызны каплаган, ул балага узган һәм ир бала тудырган. Синең белгәненчә, Аның исеме: Гайсә, Мәрьям улы, Аллаһы Сүзе һәм Аллаһы Рухы. Ул саф булган. Ул күкләрдән Аллаһы Бәрәне рәвешендә килгән. Мәсих Аллаһы каршында саф һәм камил тормыш белән яшәп, Үзенең Аллаһы Бәрәне икәнлеген исбат иткән. Аңа беркайчан да: «Бөек Аллаһының ярлыкавын үтенәм» дияргә кирәк булмаган, чөнки Ул чыннан да саф Аллаһы Бәрәне булган. Әмма Ул Аллаһы Бәрәне кебек, дөньяның гөнаһын Үз өстенә алырга килгәнлектән, Ул корбан итеп бирелергә тиеш булган. Шулай килеп чыккан да, Ул Үзе теләп, Үз тормышын корбан иткән. Әмма Ул үледән терелгән. Тере килеш Ул күккә ашкан. һәм бервакыт Ул бу дөньяга әйләнеп кайтачак.

Хәмит бераз туктап торганнан соң, Әхмәткә карады һәм әйтте:

- Минем хәлем шулай ук, Ибраһим улыныкы кебек, мин дә үлем каһәре астында. Әмма Мәсих Гайсә саф Аллаһы Бәрәне булганлыктан, минем гөнаһым өчен корбан бар.

Хәзер, бу Бәрән булганлыктан, Аллаһы безнең бар гөнаһларыбызның кичерелүен һәм җәннәттә мәңгелек тормыш тәкъдим итә. Әхмәт, синең гөнаһларыңны да кертеп, Мәсих барлык кешелек гөнаһларын Үз өстенә алган.

Әхмәт уйланып, бик озак эндәшми торды. Берникадәр вакыттан соң ул:

- Әгәр Мәсих дөньяның бар гөнаһын Үзенә алган икән, шулай булгач мин үләргә тиеш түгел... Алай бул-

гач, бу очракта минем тормышым мәңгелек, - диде.

- Әхмәт, - диде Хәмит, - менә синең туган көнең ди, һәм Мәсих синең ишегеңне шакый дип күз алдыңа китер. Аның Үзе белән бүләге дә бар, һәм Ул сиңа әйтә: «Әхмәт, Мин сиңа бер бүләк бирергә теләр идем, ә аңарда - гөнаһларыңның акланыуы, мәңгелек тормыш һәм инде бүген үк Аллаһ белән тере шәхси аралашу. Әмма аның билгеле шартлары бар. Син тәүбә кылергә, үзеңнең гөнаһларыңны әйтеп үкенергә, һәм Минем синең өчен булган корбаным аша кичерүне кабул итәргә тиеш буласың. Әгәр син бу бүләкне кабул итсәң, ул синеке, башка очракта - юк.»

Әхмәт әле генә ишеткәннәре турында уйланды. Ул бераз буталды һәм нәрсә әйтергә дә белми торды.

- Мөгаен, син нинди сәер мисал дип уйлыйсыңдыр, - диде Хәмит. - Әмма дөреслек шунда, Аллаһыга хезмәт итүче кем дә булса Мәсих аша Аллага илткән юлны аңлатканда, үледән терелгән тере Гайсә, Мәрьям улы, чыннан да Үзе безнең ишегебезне шакый дигән сүз. Ул Библиядә шулай дип әйткән дә:

***«Менә, Мин ишек төбендә шакып торам. Кем тавышымны ишетсә һәм ишекне ачса, Мин аның янына керәчәкмен һәм аның белән ашаячакмын, ә ул Минем белән ашаячак.» (3)***

Хәмит дәвам итте:

- Мәсих өчен ишек ачу һәм Ул синең белән икмәген вә аралашуын бүлешсен өчен Аны үз тормышыңа чакыру - бу Аллаһы бүләген минем дә, һәм кемнең дә булса башканың да кабул итүе дигән сүз.

- Хәмит, мин синең бу турыда белүеңне телим, - диде Әхмәт, - синең әле генә Мәсих турында әйткәннәрең мине нык дулкынландырды. Миңа әле безнең бу сөйләшүебез турында бик күп уйларга кирәк. Әмма мин киләсе очрашуларыбызда Мәсих турында тагын да күбрәк ишетергә теләр идем.

- Әс-сәламе-галәйкем.

- Мегаләйкем-әс-сәлам.

- Синең теге вакытта Мәрьям улы Гайсә турында сөйләгәннәрең мине күп уйланырга мәҗбүр итте, - дип, бик сак кына башлады Әхмәт. - Без Мәсих турында сөйләшүебезне дәвам иткәнче, син минем берничә сорау-ма җавап биреп үтсәң, үпкәләмәссең дип өметләнәм.

- Әлбәттә, әйдә, оялма, - диде Хәмит, инде Әхмәтнең нәрсә турында сөйләячәген сиземләп.

Әхмәт сак кына башлады:

- Әйе, син без, мөселманнарның, күкләр китапларына: *Тәүрәткә* (Мусаның Бишкитабына), *Зәбурга* (Давытның мәдхияләренә), Гайсәнең *Инҗиленә* һәм изге Коръәнгә ышануыбызны беләсең. Әмма мине Коръәннән кала, барлык китаплар яһүдләр һәм мәсихчеләр тарафыннан шул дәрәҗәдә бозылганнар ки, шуңа күрә анда язылганнар-га ышанырга ярамый дип өйрәтteләр. Шуңа күрә син ышана торган Изге Китап (Библия) бозылган һәм чынның ялган белән катнашмасын сурәтли.

- Ә син моңа нинди дә булса тарихи дәлилләр китерә аласыңмы? - дип сорады Хәмит.

Әхмәт бераз уйланып торды, әмма шунысы гаҗәп, тарихи дәлилләрсез генә фикер йөртүләрдән башканы ишеткән булмаганын исенә төшерде.

Хәмит дәвам итте:

- Зинһар өчен, әйт әле, бу бозылулар кайчанрак булган, һәм гомумән аны ничек гамәлгә ашырырга мөмкин булган?

- Юк, мин булдыра алмыйм, - диде Әхмәт, уңайсызла-нып. - Мондый мөһим сорауларга миңа беркемнең җавап биргәне булмады.

Бераз дәшми торганнан соң Хәмит болай дип сорады:

- Коръән шулай ук бозылган дип, күз алдыңа китерә аласыңмы?

- Аллам сакласын! - дип кычкырып җибәрде Әхмәт. - Бу мөмкин булмас иде, дин тотучылар мондый ният

белән Коръәнгә кагылучыны беркайчан да кабул итмәсләр иде.

Хәмит болай дип җавап бирде:

- Соң, шулай булгач, нигә безнең мөнәсәбәтебез Библиягә башкача дип уйлыйсың? Хак иман итүчеләр Изге Язманы үзгәртеп, Библияне боза алучыны кабул итә алырлар дип уйларга ничек батырчылык иттең? Мин күкне һәм җирне тудырган, һәм бар нәрсәне белүче, бик кодрәтле Аллага ышанам. Ул Үз Сүзен кешеләргә биргән, һәм бу Сүзне сакларлык хакимлеге дә бар.

Хәмит Әхмәткә үтәли карады һәм болай дип сорады:

- Син бар нәрсәнең дә Аллаһы ихтыяры буенча барлыкка килүенә ышанасыңмы соң?

- Әйе, - диде Әхмәт.

Хәмит дәвам итте:

- Алай булгач син чыннан да, Аллаһы башта җиргә Үз Сүзен җибәргән, ә соңыннан Ул бозылса да ярый дигән нәтиҗәгә килгән дип уйлыйсыңмы?

Әхмәт ризалышты:

- Әйе, әлбәттә, Аллаһы Үз Сүзен саклый алырлык көчле.

- Беләсеңме, Әхмәт, - диде Хәмит, - Библия - ул искиткеч китап; аны якынча 1500 ел буена язганнар! Ул Тәүрәтне дә, Зәбурны һәм Инҗилне дә, һәм тагын рәсүлләр һәм Аллаһы пәйгамбәрләре язган башка күп кенә китаплар-ны да үз эченә алган. Библия ике өлешкә бүленгән: Иске Васыять - ул Мәсих туганчы булган нәрсәләр турында сөйли, һәм Яңа Васыять - ул Мәсихнең дөньяга килүеннән башланып китә. Библия өч төрле телдә язылган.

- Нинди телләрдә? - дип сорады Әхмәт.

- Борынгы еврей (иврит), арамей (борынгы Сүрия) һәм борынгы грек телләрендә, - дип җавап бирде Хәмит.

- Аллаһы бу Сүзен төрле-төрле кешеләргә биргән: аларның кайберләре патша һәм түрәләр, икенчеләре - көтүче һәм балыкчылар булган. Библия - ул чыннан да

Аллаһының могҗизасы, чөнки күп вакыт үтүгә һәм аны күп кешеләр язуга да карамастан, барлык китап - шулай да бер бөтен. Бар Библия аша үтә торган бер тема бар. Бу тема шул Мәсих турында инде, Әхмәт.

- Чыннан да 1500 ел буена Аллаһы Мәсих турында сөйләгәнме? - дип гаҗәпләнде Әхмәт.

- Әхмәт, - дип елмайды Хәмит, - Аллаһы Мәсих турында гасырлар буена, хәзерге көннәргә чаклы сөйли.

- Бу мөмкинмени? - дип шөбһәләнде Әхмәт.

- Әлбәттә, Аллаһы бит барын да булдыра ала, - дип җавап бирде Хәмит.

- Әмма без бу турыда икенче тапкыр сөйләшербез, - диде Әхмәт.

- Әс-сәламе-галәйкем.

- Мегаләйкем-әс-сәлам.

## Аллаһының Корбаны

- Миңа Мәсихнең ничек төп тема була алуы бик кызык, - диде Әхмәт.

- Хәтерлисеңме, без Мәсих турында, безнең гөнаһны Үзенә алган Аллаһы Бәрәне дип әйткән идек? - дип сорады Хәмит.

- Әлбәттә, мин моны ничек онытыйм инде? - дип җавап бирде Әхмәт.

- Мәрьям улы Гайсәгә кадәр, Аллаһы корбаннар турында гасырлар буена өйрәтеп килгән, - диде Хәмит.

- Әмма ничек итеп соң? - дип сорады Әхмәт.

- Мәсәлән, Кәбил һәм Һәбил вакытында җирдә ничә кеше яшәгән? - дип сорады Хәмит.

Әхмәт бу сорауга гаҗәпләнде, әмма җавап бирде:

- Дүрт: Адәм, Хәува, Кабил һәм Һабил.

- Бары тик дүрт кенә, - диде Хәмит. - Әмма алар Аллаһыга бары тик корбан аша гына табынырга мөмкин булганлыгын аңлаганнар. Алар моны ничек белә алганнар? - дип сорады Хәмит һәм дәвам итте:

- Чөнки алар Аллаһының саф һәм изге, ә кешенең -

гөнаһлы, һәм гөнаһларын йолып алу өчен корбанга мохтаҗ икәнлекләрен белгәннәр.

Нух корбан аша Аллаһыга табынган; Ибраһим - шулай ук корбан аша; Муса, Давыт, бар рәсүлләр һәм пәйгамбәрләр Аллаһыга корбан аша табынганнар. Син минем дә Аллаһыга нәкъ шулай табынганымны беләсеңме?

- Юк, син хәзер шаяртасың, - диде Әхмәт. - Син бит корбан чалу өчен базарга тәкә сатып алырга бармыйсың, - дип елмайды Әхмәт.

- Мин Аллаһыга, корбан ителгән чакта, минем гөнаһларымны күтәргән Аллаһы Бәрәне, Мәсих аша табынам, - дип җавап бирде Хәмит. - Бу Изге Китапта (Библиядә) язылган:

***«Чөнки Аллаһы бер, һәм Аллаһы белән кешеләр арасында арадашчы бер, Ул - бар кешеләр котылсын өчен Үз тормышын биргән Кеше Мәсих Гайсә. (1)***

Аллаһы бары тик бер генә һәм Аллаһы белән кешеләр арасында арадашчы да бары тик бер - Мәсих, Ул Үзен барысын да, һәм, Әхмәт, сине дә йолып алу өчен корбан иткән. Барлык гасырлар буенча, һәм хәзерге көннәрдә дә кеше тере Аллаһыга корбан аша табына.

- Мин сине аңлый башладым бугай, әмма миңа бары да ачык аңлашылсын өчен, синең тагын да җентекләбрәк аңлатып бирүең кирәк, - диде Әхмәт, әле генә ишеткәннәре турында уйланып.

Хәмит уйланып торды һәм әйтте:

- Аллаһы тормышта корбанның әһәмияте һәм мәгънәсен, бигрәк тә Муса аша Тәүраттә ачык чагылдырган. Гөнаһ өчен йолып алу буларак корбанның мәгънәсе турындагы гадәти шәригать тәгълиматы, Язманың түбәндәге сүзләрендә ачык чагыла:

***Канун бар нәрсәнең диярлек кан белән пакьләндерелүен таләп итә, һәм кан түгелмичә ярлыкау булмый.» (2)***

- Әмма корбаннар турындагы бу бар тәгълимат Мәрьям улы Гайсә белән ничек бәйләнелгән соң? - дип кызыксынды Әхмәт.

- Ә менә ничек, - диде Хәмит. - Корбанның мәгънәсе турындагы тәгълимат белән беррәттән пәйгамбәрләр Мәсих турында алдан күреп, төрле-төрле пәйгамбәрлек-ләр дә сөйләгәннәр. Бу пәйгамбәрлекләр арасында Мәсих дөньяга килгәч, безнең гөнаһлар өчен йолу буларак, Ул Үзен корбан итәчәк, дигәннәре дә булган.

Хәмит Библияне ачты һәм Әхмәткә күрсәтте.

- Мәсихнең корбаны ничек сурәтләнгәнен үзең кара һәм җентекләп укып чык; моны пәйгамбәр Ишагыйя Мәсих килгәнгә кадәр якынча 700 ел кала язган:

***«Ләкин Ул безнең чирләребезне Үз өстенә алды вә шулар белән яшәде; ә без Ул Аллаһы тарафыннан кыйналган, җәза бирелгән вә кимсетелгән дип уйладык. Әмма Ул безнең гөнаһларыбыз өчен авырды вә безнең явыз эшләребез өчен газап чикте; Без яшәгән дөнья өчен җәзаны Ул алды, Аның җәрәхәтләре аркасында сихәтләндек без. Без барыбыз да сарыклар кебек адашып йөрдек, һәркем үз юлына кереп китте; һәм Раббы безнең гөнаһларыбызны Аның өстенә салды. Аны җәзаладылар, ләкин Ул Үз иреге белән газап чикте, һәм авызын ачып, бер сүз дә әйтмәде. Суярга сарык күк алып барылды, һәм йонын алучы алдында юашланып калган бәрән күк булды, Ул да авызын ачып, сүз әйтмәде». (3)***

Әхмәт, бу пәйгамбәрлек сүзен ишетеп бик дулкынлан-ды һәм гаҗәпләнеп әйтте:

- Нәрсә, бу чыннан да Мәрьям улы Гайсә туганчы күп гасырлар элек язылганмы әллә?

- Әлбәттә, - диде Хәмит. - һәм пәйгамбәрлек буенча, Мәсих Давыт пәйгамбәр нәселеннән чыгарга тиеш булган. Мәсихкә кадәр 1000 ел элек яшәгән Давыт, үзенең киләчәк токымы Мәсихнең хачка кадаклануын, төп-төгәл итеп тасвирлап бирә диярлек. Хачка кадаклану ул үлем җәзасының иң озак һәм газаплы ысулы булганын син беләсең бит. Берникадәр вакыттан соң хачка кадаклаган-нарның сөякләре буыннарыннан куптарылып чыкканнар, һәм шуның өстәвенә алар нык сусаудан газап чиккәннәр. Давыт пәйгамбәр болай яза:

***«Су шикелле коелдым; бар сөякләрем дә таралыштылар; эчемдә йөрәгем, эрегән балавыз кебек булды. Көчем чүлмәк китеге кебек корыды; телем тамагыма ябышты, мине үлем туфрагына төшердең. Мине күп этләр чорнап алды, яманнар җыены мине чолгап тотты, кулларымны да, аякларымны да чәнечтеләр. Бар сөякләремне санап чыгарлык иттеләр, ә үзләре карап торып мине мыскыл итәләр; киемнәремне үзара бүлешәләр, өс киемемә җирәбә салалар.» (4)***

Ул вакытларда үлем җәзасының бу төре бөтенләй кулланылмауга да карамастан, бу төгәл тасвирламаны Давыт язган. Хачка кадаклау күпкә соңрак уйлап табылган, һәм аны римлылар Мәсих яшәгән вакытларда кулланганнар.

- Мин болай аңлыйм, син алдан белеп әйтелгәннәрнең барысы да Мәрьям улы Мәсихтә тормышка ашты дип әйтергә телисең, - диде Әхмәт.

- Әйе, әле болар гына түгел, һәм тагын башка бик күп алдан белеп әйтелгәннәр дә Мәсихтә тормышка ашты, - диде Хәмит. - Кайбер очракларда Мәсих Үзе дә, тормышын фида кылу өчен килгәнлеген раслап, Ул Үзе үк Үзе турында мондый сүзләр әйтте:

***«Адәм Улы да бит, Үзенә хезмәт итсеннәр өчен дип килмәде, ә Үзе хезмәт итеп, күпләрне йолып алу өчен Үзенең тормышын бирергә дип килде.» (5)***

- Әхмәт, Аллаһының корбаннар турындагы тәгълимат-ы бөтен Библия аша үткәнен һәм барсының да Мәсихтә тормышка ашуын, син хәзер күрәсеңме?

- Хәмит, минем бу турыда элек беркайчан да ишеткәнем булмады, - диде Әхмәт. - Бу, әлбәттә, бик кызыклы. Миңа болар турында уйланырга әле тагын вакыт кирәк, әмма син борчылма, мин тиздән тагын килермен, һәм минем сиңа сорауларым тагын да күбрәк булыр.

- Әхмәт, бу Библия сиңа миннән бүләк, - диде Хәмит. - Яңа Васыятьтән укый башла, син аннан Мәсихнең тормышы, Аның искиткеч могҗизалары һәм өйрәтүе

турында укый аласың.

- Бик зур рәхмәт, - диде Әхмәт. - Мин *«Китап (Тәурат, Зәбур һәм Инҗил) әһелләре»* турында күп ишеттем, әмма китапның үзен беркайчан да укыганым булмады. Минем чыннан да Мәрьям улы Гайсәнең могҗизалары һәм өйрәтүе турында бик укыйсым килә.

- Әс-сәламе-галәйкем.

- Мегаләйкем-әс-сәлам.

## Гөнаһ

- Хәмит, - дип шактый сузып, сүзен башлады Әхмәт. - Беләсеңме, безнең соңгы очрашуыбыздан соң мин Мәсих турында, Аның бар кешелек гөнаһлары өчен ничек Үз гомерен корбан итүе хакында уйладым. Әмма мин аңламаган бер нәрсә бар - гөнаһ кайдан килә соң? Ни өчен бар кешеләрнең гөнаһ аркасында мәсьәләләре булуын аңлатммассыңмы икән? - дип, бик җитди рәвештә сорады Әхмәт.

- Аңлатып бирә алырмын дип уйлыйм, - диде Хәмит. - Әмма безгә гөнаһның кайдан килеп чыгуын аңлау өчен, иң баштан башларга кирәк булыр.

Аллаһы дөньяны һәм кешелекне тудыргач, Ул кешене җәннәткә урнаштырган. Без бу турыда Тәураттан укыйбыз. Кеше җәннәттә бик саф булган һәм Аллаһы белән тулысынча килешеп яшәгән. Әмма бер вакыйгадан соң җәннәттәге бу тормыш бозылган, шулай бит? Әхмәт, анда нәрсә булган соң?

- Иблис килгән дә, барын да җимереп ташлаган, - диде Әхмәт.

- Дөрес! - диде Хәмит. - Аллаһы кешегә яхшылык һәм явызлыкны танып-белү агачыннан җимеш ашамаска кушкан, һәм Адәмгә әйткән:

***«Бакчадагы теләгән һәр агачның җимешен ашарга рөхсәт; әмма яхшылыкны һәм яманлыкны таныта торган белем агачыннан ашама; чөнки ул агачның җимешен ашаган көнне үк мотлак үләчәксең.» (1)***

Ләкин елан кыяфәтендә бакчага шайтан килгән һәм Адәм белән Хәуваны вәсвәсәләндергән; алар Аллаһыга буйсынмый башлаганнар һәм тыелган агачтан җимеш ашаганнар. Бу яман эш кешелекне һәлакәтле нәтиҗәләргә илткән - шул вакыттан соң гөнаһ кеше эченә үтеп кергән һәм аның бер өлешенә әйләнгән, һәм кешеләр шул рәвешчә гөнаһлы булганнар.

- Син бар кешеләрнең дә гөнаһлы икәнлекләренә ышанасыңмы соң? - дип шикләнеп сорады Әхмәт. - Миңа моны кабул итүе җиңел түгел. Ничек алар барысы да гөнаһлы булганнар?

- Кеше нәкъ, ул ашаган җимеш шикелле булган, - диде Хәмит. - Ул яхшылык һәм явызлыкның сәер катнаш-масына әйләнгән. Башта шул ук кеше бик яхшы һәм игелекле эшләр башкара, ә аннары нинди дә булса мәкерле эш кыла, яки үз якынының малын үзләштерә ала. Бер яктан кеше яратучан һәм кайгыртучан, ә инде икенче яктан көнче, нәфрәт итүче, үз-үзен генә яратучы һәм башка гөнаһлы сыйфатларга да ия була ала.

- Әхмәт, син әйткәнчә, бу мәсьәлә һәркемдә дә бар. Бар диннәр дә бу мәсьәләне хәл итәргә тырышып карый; бар дәүләтләр дә гөнаһ кимесен өчен төрле каннуннар чыгара. Мөгаен иң начары шулдыр, кеше гөнаһ кылган-га гөнаһлы түгел, бәлки киресенчә - ул гөнаһлы булганга күрә гөнаһ кыла. Бу һәрбер кешедә, гөнаһ һәм явызлык эшләп чыгара торган кечкенә генә фабрика бар кебек. Бу шулай түгелмени? - дип сорады Хәмит, Әхмәткә игътибар белән карап.

- Син кеше турында бик дөрес әйттең, кызганычка каршы моның белән килешергә туры килә. Кеше чыннан да яхшылык һәм явызлыкның ниндидер сәер катнашмасы, - дип җавап бирде Әхмәт. - Әмма монда шайтанның ни катнашы бар?

- Аңлыйсыңмы, гөнаһ аркылы шайтан кеше тормышы һәм бөтен бер җәмгыять өстеннән хакимлек алды, - диде Хәмит. - Ул, кайчандыр Адәм белән Хәуваны

вәсвәсә-ләндергән кебек, хәзер дә шул ук рухта дәвам итә. Без гөнаһлы килеш яшәүбезне дәвам итсен өчен, ул кешеләрне нәкъ шулай ук вәсвәсәләндерә. Безне Аллаһыдан гөнаһ аерып торганлыктан, иблис гөнаһ аркылы безнең тормы-шыбыз өстеннән хакимлек итә. Нәкъ менә шул гөнаһ аркасында бүген дөнья шундый коточкыч хәлдә.

Аллаһы Тәгалә бар нәрсәне дә бик гүзәл итеп яраткан, әмма кеше дөньяга күп афәтләр китергән - мәсәлән, халыклар арасында сугышлар, изүләр, аннары кешеләр арасындагы дөрес булмаган барлык мөнәсәбәтләр, һәм кешенең җирдәге тормышын җимерәп торган, башка бик күп төрле явызлыклар.

- Шулай итеп, Аллаһы чынлыкта исә безне бөтенләй мондый итеп яратмаган, ә дөньяның бүгенге халәте - бу Адәм кылган гөнаһның нәтиҗәсе, син шуны әйтергә телисеңме? - дип сорады Әхмәт.

- Әйе, әлбәттә, - диде Хәмит. - Түбәндә язылганча, гөнаһ кешегә Адәм аркылы үтеп кергән:

***«Бер кеше аркылы гөнаһ һәм гөнаһ белән бергә үлем дөньяга үтеп керде. Шулай итеп, үлем барлык кешеләргә таралды, чөнки барлык кешеләр гөнаһ кылдылар.» (2)***

Тәннең, шулай ук рухның да үлеме - гөнаһның иң яман нәтиҗәсе булган.

- Тән һәм рухның үлеме? - дип сорады Әхмәт һәм гаҗәпләнеп, Хәмиткә карады. - Ә нәрсә соң ул рухи үлем?

- Аллаһы кешегә, әгәр ул шул җимешне ашаса, һичшиксез, үләчәк дигән, - дип җавап бирде Хәмит.

- Аллаһы гадел һәм һәрвакыт Үз Сүзен тотканлыктан, кешелек үлемгә дучар булган, һәм шул көннән башлап, иртәме-соңмы һәркем үлем белән очрашырга тиеш булган. Әмма кеше гөнаһ кылгач, ул тагын рухи яктан да үлгән.

- Бу ничек була соң? - дип сорады Әхмәт.

- Гөнаһ нәтиҗәсендә кешене җәннәттән куып

җибәргәннәр, - диде Хәмит. - Ул Аллаһы белән саф һәм яхшы мөнәсәбәтләрдә яшәгән җиреннән куылган, һәм аңа җәннәттән читтә яшәргә туры килгән. Үзенең гөнаһы аркасында тере һәм изге Аллаһыдан аерылгач, кеше рухи яктан үлгән. Шулай итеп, кешенең гөнаһы һәм явызлыгы аны Аллаһыдан аерып тора. Нәкъ менә гөнаһ аркасында кеше бүтән Аллаһы белән якыннан аралашып яшәми. Аллаһы саф һәм изге булганлыктан, Аның гөнаһ белән бернинди элемтәсе дә юк, һәм нәкъ менә шуңа күрә безне гөнаһның бар ләгънәтләреннән коткара алырлык Коткаручы кирәк.

- Әхмәт, син үзеңнең бар гөнаһларың да язылган дип ышанасың бит?

Әхмәт, бераз уңайсызланып, болай диде:

- Мин беләм, аларны һәрбер кешегә ияреп йөрүче, ике фәрештә язып бара.

- Аллаһы безнең хакта барсын да белә, - дип дәвам итте Хәмит. Һәрбер яхшы һәм яман эшне, һәрбер сүз, уй һәм ниятне. Аларның һәрберсе Аллаһыда язылган. Син беләсеңме, синең эшләрең кыямәт көнендә ничек бәяләнерләр?

- Юк, бары тик Аллаһы кына белә, - дип, әкрен генә әйтте Әхмәт.

- Әхмәт, Аллаһы сине ярата. Аллаһы Бәрәне Мәрьям улы Гайсә безнең бар гөнаһларыбызны Үзенә алып китте, шуны исеңдә тот. Бар нәрсә өчен дә ярлыкау бар, - диде тыныч кына Хәмит.

Әхмәт бераз уйланып торганнан соң әйтте:

- Әгәр Мәсих шулай мөһим икән, ул чакта нигә соң Адәм белән Хәува Аның турында ишетмәгәннәр?

- Әгәр алар Мәсих турында ишеткән булганнар дисәм, син ышанырсыңмы соң? - диде Хәмит.

- Юк, Адәм белән Хәуваның Аның турында ишетә алулары бөтенләй мөмкин түгел, - дип гаҗәпләнде Әхмәт.

- Аллаһы кешене ярата һәм аның белән аралашырга тели, - дип җавап бирде Хәмит. - Менә шуңа күрә Ул иң

беренче Мәсих турында сөйли башлаган. Адәм һәм Хәува белән булган шул фаҗигага да карамастан, аларга көннәрдән беркөнне кеше өстеннән шайтан хакимлеген җимереп ташлый торган азат итүче турында бер вәгъдә бирелгән булган. Аллаһы иблискә әйткән, ә Адәм белән Хәува моны ишеткәннәр:

***«Синең белән хатын, синең токымың белән аның нәселе арасында дошманлык җебе сузачакмын. Аның нәселе сиңа сугып башыңны ярыр, син исә аның үкчәсен чагарсың.» (3)***

Библиядә угылларны һәрвакыт атасы исеме белән атап йөрткәннәр - Ибраһим улы, Якуп улы һәм башкалар, әмма монда «хатынның нәселе» турында язылган. Көннәрдән беркөнне бары тик хатынның гына улы булган, ягъни атасы булмаган Кемдер килер. Шайтан, елан кебек, аның «үкчәсен» чагар, үтерергә тырышып караса да, бу угыл иблиснең кеше өстеннән хакимлек итүен җимерер.

Бу - Мәрьям улы Гайсә белән Ул кешелек гөнаһларын йолып алу өчен Үзен корбан иткән чакта булганнарның төгәл тасвирламасы.

- Менә ничек яхшы, - диде Әхмәт. - Аллаһының инде җирдәге иң беренче кешеләрне үк Мәсих турында өйрәтә башлавы бик әйбәт, һәм бу Библия әйткәнчә, Мәсихнең чыннан да бик мөһим икәнлеген тагын бер тапкыр исбат итә. Хәмит, безнең киләсе очрашуыбызга чаклы уйланыр өчен син миңа тагын күп азык бирдең.

- Әс-сәламе-галәйкем.

- Мегаләйкем-әс-сәлам.

## Ибраһим улы

- Әхмәт, - син Инҗил турында нәрсә уйлыйсың? Мине бу сорау бик кызыксындыра. - диде Хәмит.

- Бу чыннан да иң мавыктыргыч китап, - диде чын күңеленнән Әхмәт. - Моңарчы беркайчан да моңа охшашлы китап укыганым булмады, һәм Мәсихнең бөек

могҗизалары турында уку чиктән тыш кызык, а Аның тау битендәге вәгазе чыннан да искиткеч. Бу тәгълимат шундый ачык аңлаешлы һәм тирән мәгънәле. Ул күп нәрсәләрне бөтенләй «баштан аякка» әйләндергән, мәсәлән, дошманнарны яратырга һәм сезне куучылар өчен дога кылырга өйрәткән.

Аның дога турындагы тәгълиматы, минем бу турыда элек ишеткәннәрдән бик аерылып тора. Бу китап миндә шундый көчле тәэсир калдырды, әмма шуңа да карамас-тан, мин никадәр сорауларыма җавап тапкан булсам, миндә шулкадәр диярлек үк яңа сораулар барлыкка килде.

- Ә, менә бу бик кызык, - диде Хәмит елмаеп. - Әйдә, синең беренче соравыңнан башлыйк.

- Ничек телисең, - диде Әхмәт. - Шулай итеп, нигә Инҗил Мәсих шәҗәрәсеннән башлана - Давыт аша Ибраһимнан һәм Мәсихнең Үзенә кадәр?

Хәмит бер минут уйланып торганнан соң әйтте:

- Хәтерлисеңме, без элек Библия - ул бер бөтен, һәм анда бар китап дәвамын да сөйләнелә торган бер тема барлыгы турында фикер алышкан идек?

- Әйе, хәтерлим, - диде Әхмәт.

- Син аның нинди тема икәнен хәтерлисеңме?

- Мәсих турында, - диде Әхмәт.

- Синең соравыңа җавап бу тема белән бәйләнгән, - диде Хәмит. - Пәйгамбәрлек буенча, Мәсих Ибраһим улы һәм Давыт улы булырга тиеш булган.

Әхмәт әле генә Хәмит әйткәннәр өстендә бераз уйланып торганнан соң, ниһаять болай диде:

- Бу бик кызык, бәлки син бу пәйгамбәрлекләр турында тагын бер кат, тулырак итеп аңлатырсың?

Бераз торганнан соң, Хәмит болай дип башлады:

- Аллаһы кайчандыр, якынча 4000 ел элек, хәзер Аллаһының дусты дип атала торган, Ибраһимга мөрәҗәгать иткән. Ибраһимга (аны ул вакытта Абрам дип атаганнар) Аллаһы бер әйбер вәгъдә иткән. Ул Ибра-

һимга әйткән әйбер, барлык кешелек өчен бөек нәтиҗәләргә ия булырга тиеш булган. Тәураттан (Мусаның Бишкита-бы) без боларны укыйбыз:

***«Раббы Ибраһимга әйтте: торган җиреңне, халкыңны, атаң йортын калдыр. Мин күрсәтәчәк җиргә күчеп кит. Синең нәселеңнән Мин бөек халык тудырачакмын, сине мөбарәк кылачакмын, исемеңне шөһрәтле итәчәкмен; син фатиха-бәрәкәт булачаксың. Сиңа изгелек теләгәннәргә Мин изгелек эшләячәкмен, сине каһәрләгәннәргә ләгънәтемне яудырачакмын. Җир йөзендәге кавемнәрнең һәммәсе синең аша Минем фатихамны алырлар.» (1)***

Инде күптән өйләнгән булса да, балалары булмаган бер кешене Аллаһы Үзенә чакырган. Аллаһы аңа җир бирергә, һәм аннан бөек халык тудырырга вәгъдә иткән, һәм аның исеме зур һәм танылган булачак дигән. Аллаһы Үзенең бар вәгъдәләрен төп-төгәл үтәгән, әмма нәзер-ләрнең гаҗәбе соңгысы - ягъни Ходай Аллаһының Ибраһим аркылы җирдәге бар халыкка фатиха бирүе булган. Бу вәгъдәдә Мәсих турында нәзер тора. Димәк, Мәсих Ибраһим улы булырга тиеш булган, һәм Аның аша Аллаһы бөтен дөньяны фатихалы итә алган.

- Әмма син бу нәзернең Мәсихкә, яки тагын башка берәүгә кагылышлы булуын каян белә аласың? - дип сорады Әхмәт.

- Тәуратны укуны дәвам иткән вакытта, бу ачык аңлашыла, - дип җавап бирде Хәмит. - Берникадәр вакыт үткәч, Ибраһимның ике улы дөньяга килә, берсе - Исхак исемлесе - аның хатыны Сарадан, ә икенчесе - Сараның хезмәтчесе Һаҗәрдән, аның исеме - Исмәгыйль була. Әмма Аллаһы Исмәгыйльгә фатихасын бирсә дә, Мәсих турындагы нәзер Исхак аша тормышка ашарга тиешле-ген, Исхак туар алдыннан, Ул Ибраһимга бик ачык итеп әйткән:

***«Нәкъ менә хатынын Сара сиңа угыл табып бирер. Аңа син Исхак дип исем кушарсың. Мин аның белән һәм аның аша нәсел-нәсебе белән Антлашу килешүемне мәңгегә беркетеп куячакмын. Исмәгыйльгә килгәндә, Мин сине ишеттем. Аңа***

***мөбарәк кылып, нәселен бик үрчемле, бик ишле итәчәкмен. Аңардан унике хан туар; нәселеннән бөек халык барлыкка килер. Әмма Антлашу килешүем Мин Исхак белән ныгытып куячакмын.» (2)***

- Әйе, Аллаһы фатихасын алган Исмәгыйль, гарәпләрнең атасы булган, - диде Әхмәт. Әмма без, мөселманнар, Аллаһының Исхак токымыннан күп рәсүлләр һәм пәйгам-бәрләр җибәрүен беләбез.

Хәмит дәвам итте:

- Исхакның Эсау һәм Якуп исемле ике улы булган. Аллаһы, вәгъдә ителгән Мәсихнең Якуп токымыннан киләчәген күрсәткән, Ул Үзе ничек аңа төшендә ачкан һәм әйткән:

***«Мин – Раббы, бабаң Ибраһим һәм атаң Исхакның Алласымын. Син ятып йоклаган бу җирне Мин сиңа һәм синең нәсел токымнарыңа бирәчәкмен. Синең нәселеңнең киләчәк буын кешеләре җир йөзендәге ком бөртекләре санынча булачак. Синең нәсел диңгез ярларына таба да, көнчыгышка, төньякка, төшлек ягына таба да – һәр тарафта ишәеп таралыр.» (3)***

- Шушы гаҗәп, Аллаһы Ибраһимга әйткән сүзләрен, төп-төгәл диярлек Якупка да әйткән, - диде Әхмәт.

- Чөнки бу асылда, буыннан буынга тапшырылып килгән бер үк вәгъдә булган, - дип җавап бирде Хәмит. - Әхмәт, ләкин син күргәнчә, Аллаһы җирдәге бар халыкка нәкъ менә Якупның токымы аша фатихасын бирергә теләгән.

- Әйе, мин Библиянең төп темасы яңадан Мәсих булачак дип уйлый башладым, - диде Әхмәт, елмаеп.

- Дөрес, - диде Хәмит. - Шулай менә, Исраил балалары арасында күп гаиләләр булган. Аллаһы Мәсихнең кайсы гаиләдә яки кайсы нәселдән чыгачагын ачканмы соң дигән сорау туа. Аллаһы Давытны сайлаган һәм аның белән килешү төзегән. Аллаһы Үзенең күп пәйгамбәрлекләрендә Мәсихнең Давыт нәселеннән булачагын ачкан. Давыттан соң, ике йөз елдан артык яшәгән Ишагыйя пәйгамбәр, Йишай нәселен киселгән агачка охшаткан.

Сүз уңаеннан әйтеп китик, Давытның атасы Йишай исемле булган. Аллаһы Рухы иңәсе кеше бу гаиләдән чыгачак дигән Иша-гыйя. Ул бу дөньяның ярлыларына гадел хөкем алып килер, Ул оҗмахка охшашлы Патшалык тудырыр, һәм бу пат-шалыктагы һәркем Ходайны белер. Ишагыйя болай яза:

***«Шуннан соң Йишай тамырыннан бер үсенте, тамырыннан бер ботак үсеп чыгачак. Һәм Анарда Раббы Рухы, зирәклек һәм акыл рухы, киңәш вә ныклык рухы, әйдәп бару вә тәкъвалык рухы яшәячәк... Ярлыларны Ул дөреслек белән, җирдә җәфа чигеп яшәгәннәрнең эшләрен хакыйкать кушканча хәл итәчәк... Һәм ул көнне халыклар өчен байрак булачак, Йишай тамырына мәҗүсиләр киләчәк һәм Аның тынычлыгы данлы булачак.» (4)***

- Хәзер карап карыйк, мин дөрес аңладыммы икән, - диде Әхмәт. - Димәк, Аллаһы Мәсихнең Ибраһим, Исхак, Якуп һәм Давыт нәселеннән булачагын ачкан.

- Дөрес! - диде Хәмит елмаеп. - Һәм без Инҗилне укыганда, Мәсихнең пәйгамбәрлекләргә туры килеп туган-лыгын күрә алабыз. Менә шуның өчен Инҗил, Мәсихнең Ибраһим улы һәм Давыт улы икәнен күрсәтә торган нәсел шәҗәрәсе белән башлана.

- Билиянең төп темасы - Мәрьям улы Гайсә икәнлеге, тагын бер кат расланды, - диде Әхмәт. - Ләкин син инде үзең дә аңлыйсыңдыр, әле минем сиңа тагын бик күп сорауларым бар, без алар турында киләсе очрашуыбызда сөйләшербез.

- Әс-сәламе-галәйкем.

- Мегәләйкем-әс-сәлам.

## Аллаһы бераү генә

- Син хәзер нәрсә күрәсең? - дип сорады Әхмәт, өч бармагын күрсәтеп.

- Бер кулның өч бармагын күрәм, - диде Хәмит, елмаеп, чөнки ул Әхмәтнең нәрсә уйлаганын чамалый иде.

- Хәмит, - дип дәвам итте Әхмәт, - син ничек уйлыйсың, Аллаһы берәү генә яки алар өчәү?

- Ихтимал, син минем ничек иман итүемне ахырына чаклы аңлый алмассың, - дип җавап бирде Хәмит,

- әмма сиңа шуны аңларга кирәк, мин күкне һәм җирне тудырган, чиктән тыш куәтле, бар нәрсәне белүче, һәр кайда булучы бердәнбер Аллаһыга иман итәм.

Минем иман итүем Библиягә нигезләнгәнен син беләсең, ә Библия Аллаһы берәү генә дип өйрәтә; бу хакыйкать Библиянең күп урыннарында язылган.

- Әмма Аллаһы бер үк вакытта өчлекле һәм бердәнбер була алмый, - диде Әхмәт, яңадан өч бармагын күтә-реп һәм өстәде:

- 1 + 1 + 1 = 3, ә бер түгел.

- Син ничә Әхмәттән торасың, берме яки икеме?

- дип сорады Хәмит. - Әлбәттә, бер, - диде Әхмәт.

- Әмма Аллаһы сине тән һәм рух белән тудырган,

- диде Хәмит. - Синең тәнең - ул Әхмәтме?

- Әлбәттә, - диде Әхмәт.

- Ә синең рухың - бу шулай ук Әхмәтме? - дип сорады Хәмит.

- Әйе, - диде Әхмәт, Хәмитнең сүзне нәрсәгә таба баруын аңламыйча.

Хәмит дәвам итте:

- Әгәр Ул безнең һәрберебезне бердә ике итеп тудырган икән, Аллаһының бердә өч булуы ни өчен мөмкин түгел соң?

Хәмит бер минут эндәшми торганнан соң, дәвам итте:

- Аллаһы - Ул бер бөтен, Ул кемдер Бер, Ул Үзен өч затта күрсәтә дип фараз кылыйк, шулай булгач 1 x 1 x 1 ничә була?

- Бер, - диде әкрен генә Әхмәт. - Әмма Марьям улы Гайсә - ул бит бары тик кеше, ә Аллаһы Улы түгел, - Әхмәт игътибар белән Хәмиткә карады. - Син ничек уйлыйсың: Мәсих - ул Аллаһы Улымы?

- Ә син, мин ничек исәплим, дип уйлыйсың? - дип сорады Хәмит.

- Мин бик үк ышанып әйтә алмыйм, - дип җавап бирде Әхмәт. - Әмма болай уйлыйм, Аллаһы Мәрьям Туташ белән җенси мөнәсәбәттә булган, һәм аларның уллары туган, син, мөгаен, шуңа ышанасыңдыр.

- Аллам сакласын! - дип кычкырып җибәрде Хәмит. - Мин бөтенләй болай уйламыйм, һәм Мәсихнең өммәтләреннән моңа ышанучы беркемне дә белмим.

Әхмәт бик гаҗәпләнде һәм сорады:

- Алай булгач, син нәрсәгә ышанасың соң?

- Мин Аллаһының мәңгелек икәненә ышанам; нәрсә дә булса тудырылганга кадәр, Ул мәңгелектә булган, - диде Хәмит. - Инҗил Мәсихнең кемлеген аңлатканда, ул Аның дөньяга килүеннән башламый; юк, Инҗил мәңгелектән, Аллаһы дөньяны тудырганга кадәр башлана. Инҗилдә язылган:

***«Иң башта Сүз булган, Сүз Аллаһы белән булган, һәм Сүз Аллаһы булган. Сүз иң башта үк Аллаһы белән булган. Бар нәрсә Сүз аша яратылган, һәм яратылган һәр нәрсә Аннан башка яратылмаган. Аңарда тереклек булган...» (1)***

Аллаһы дөньяны сүз белән тудырган, дөрес бит?

- Әйе, бу дөрес. Аллаһы әйткән: булсын! һәм булган, - диде Әхмәт.

- Шулай итеп Аллаһы дөньяны Үзенең Сүзе белән тудырган, - диде Хәмит. - һәм Аллаһыдан чыккан бу Сүз Аллаһының өлеше булган һәм Аллаһының төзүче вә тудыручы көче үтәлгән, һәм бу Сүз кая гына юнәлмәсен, анда күпьяклы тереклек барлыкка килгән.

- Әйе, мин килешәм, әмма *«Сүз Аллаһы булган»* дигән әйтемнең төгәл мәгънәсе ничек? - дип сорады Әхмәт.

- Мисал өчен әйтик, мин судка шаһит булып бардым ди, анда мине минем сүзләремнән аерып алырга ярамас иде, - дип җавап бирде Хәмит. - Минем сүзләрем минем вәкилем һәм өлешем булыр иде. Без монда синең белән сөйләшеп утырганда, безнең сүзләребез безнең

өлешебез булып тора, димәк, безнең сүзләребез безнең вәкилләребез булып тора. Аллаһы галәмне тудырган вакытта, Ул әйткән сүз Аның белән бердәм булган; син Алланы Аның Сүзеннән аерып ала алмыйсың. Бу Аның белән бердәм булып һәм Үз эчендә Аның барлык сыйфатларын алып килүче, Аллаһының мәңгелек Сүзе Мәрьям улы Гайсәдә күрсәтелгән булган. Бу турыда түбәндә болай язылган:

***«Сүз кеше булды, мәрхәмәт һәм хакыйкать белән тулы булып, безнең арабызда яшәде, һәм без Аның данын, Атаның бердәнбер Улына биргән данын күрдек.» (2)***

Хәмит дәвам итте:

- Аллаһы Үзе турында әйткәннәрнең барысы, Аның барлык сыйфатлары Мәсих аша күрсәтелгән булган.

- Аллаһы изге. Кешеләр Мәсихнең изгелеген күргән вакытта Аңарда Аллаһының изгелеген күргәннәр.

- Аллаһы - Ул мәхәббәт. Алар Мәсихнең кешеләрне ничек яратуын күргән чакта Аңарда Аллаһының мәхәббәтен күргәннәр.

- Бар кодрәт һәм вәкаләт Аллаһыда. Кешеләр Гайсәнең ничек су өстеннән йөрүен, көчле җилләргә әмер биреп, аларны буйсындыруын, икмәкне күбәйтүен, сукырларны савыктыруын һәм үлеләрне терелтүен күргән вакытларда алар Аллаһының Үз кодрәтен, вәкаләтен һәм данын Аңарда күрсәтүен күргәннәр.

- Әмма Аллаһы Үзен бары бер кешедә генә чикләгән чагында, Ул ничек һәр җирдә дә булуын дәвам итә алган? - диде Әхмәт. - Нәрсә, Аллаһы Мәсихтә булган чагында, әллә Ул берникадәр вакыт галәм белән идарә итми торганмы?

- Әхмәт, - диде Хәмит, - без синең белән иксез-чиксез океанда дип күз алдына китер; без океаннан бер стакан су алдык, ди. Әгәр без бу суның анализын ясасак, стакандагы су океандагы су кебек үк сыйфатларга ия булуын күрер идек. Мәсих белән дә шул ук хәл. Чиксез куәтле мәңгелек Аллаһы бар җирдә дә бар, һәм шул ук

вакытта шул ук сыйфатлар һәм шул ук вәкаләт белән Ул Үзен Мәсихтә күрсәтә. Шул ук вакытта Аллаһы Үзен Мәсихтә күрсәтеп кенә чикләнмәгән. Ул элеккечә иксез-чиксез.

- Әмма Аллаһы Үзен адәм затында күрсәтә алмый, - диде Әхмәт.

- Без ничек Аллаһыны чикли алабыз? - дип сорады Хәмит. - Без ничек кодрәтле турында - *«Ул булдыра алмый»* дип әйтә алабыз? Ул барын да эшли алмыймы әллә?

- Әйе, әлбәттә, Ул бар нәрсәне дә эшли ала, - дип җавап бирде Әхмәт. - Әмма мин Аның Үзен кеше сурәтендә күрсәтүенә ышана алмыйм.

- Яхшы, бу мәсьәләнең Аллаһы өчен түгел, безнең өчен булуы белән килештек, чөнки Ул нәрсә тели, аның барсын да эшли ала, - диде Хәмит. - Әгәр моны элек белмичә, син, Аллаһы Үзен янып торган куак эчендә күрсәткән һәм аннан Муса белән сөйләшкән дип ишетсәң, нәрсә әйтер идең?

Әхмәт бераз уйланып торды һәм үз уйларына елмаеп куйды, чөнки ул аңлады, Аллаһы өчен кеше сурәтендә күренү, куаклар эчендә күренүгә караганда, авыррак түгел иде.

Хәмит дәвам итте:

- Әхмәт, азрак уйла әле - «Аллаһы Сүзе» һәм «Аллаһы Рухы» дип аталучы чынлыкта исә Кем соң Ул?

Хәтта Аллаһы Рухы - Аллаһы белән бер үк. Без беләбез, Аллаһы Рухы Мәрьям Кызга иңгән, ул балага узган һәм Мәсихне тудырган. Аңа Җәбраил фәрештә болай дип әйткән:

***«Сиңа Изге Рух иңәчәк, һәм синең өстеңә Аллаһы Тәгаләнең кодрәте төшәчәк; шуңа күрә син тудырачак Бала изге булачак һәм Аллаһы Улы дип аталачак.» (3)***

Шул рәвешчә дөньяга килүче кем соң ул? - дигән сорау туа.

Әхмәт, син үзеңне Мәсих туган вакытлардагы та-

биб дип күз алдыңа китер, һәм сиңа Аның туу турында таныклыгын тутырырга кирәк булыр иде. Син аны ничек тутырыр идең? Син нинди исем куяр идең?

- Мөгаен, мин «Мәрьям улы Гайсә», дип язар идем, - диде Әхмәт.

- Ягъни анасының исеме? - дип сорады Хәмит.

- Бу Мәрьям Кыз булыр иде, - диде Әхмәт.

- Һәмниһаять бездән атасының исемен язу таләп ителә, - диде Хәмит, елмаеп.

- Аның атасы булмаган, - дип җавап бирде Әхмәт, көлемсерәп.

- Без, әлбәттә, бу баганага сызык куя алган булыр идек, чөнки Аның җирдәге атасы булмаган, - диде Хәмит. - Яки Аның кайдан килүен без үзебездән сорый алыр идек? Аллаһ Сүзе һәм Аллаһы Рухы дип аталучы, кайдан килеп чыккан? Күкләрдән иңгән чынлыкта исә Кем соң Ул? Ул Үзе болай ди:

***«Күктән иңеп, дөньяга тормыш Бирүче - Ул Аллаһы икмәге... Мин - тормыш икмәге: Минем янга килүче һичкайчан ачыкмас, Миңа иман китерүче һичкайчан сусамас» (4)***

***«Мин - күктән иңгән тере икмәк, бу икмәкне ашаучы мәңге яшәр. Мин бирәчәк икмәк исә - ул Минем тәнем. Мин аны дөнья яшәсен өчен бирәчәкмен.» (5)***

- Әхмәт, Ул Үз тәнен кешелек хакына корбан итү өчен килгән. Кем гади икмәк ашый, ул үзенең физик тормышын тукландыра һәм саклый. Ә кем күкләрдән иңгән Аллаһы икмәген ашый, рухи тормыш, мәңгелек тормыш ала. Кем Мәсихкә иман итә һәм Аның өлешенә ия, рухи ачлыкны һәм сусауны - Аллаһыга сусауны баса торган тормыш ала. Мин моны үз башымнан кичердем! Әхмәт, Мәсих - Ул синең өчен Аллаһының корбаны.

- Әле мин моңа әзер түгел, - диде Әхмәт әкрен генә. - Минем башымда төрле уйлар кайнаша. Мин аңлыйм, синең Аллаһыга иман итүеңне мин бөтенләй дөрес аңламаганмын, һәм хәзер мин зур кыенлык белән синең бер-

дәнбер Аллаһыга ышануыңны, һәм Ул Үзен Мәсихтә күрсәтүен аңлый башладым. Син беләсең, мин Мәсихне чын күңелдән яратам, әмма әле минем җавап таләп итә торган күп кенә сорауларым бар. Хәмит, без аларга киләсе очрашуыбыз вакытында мөрәҗәгать итәрбез дип уйлыйм.

- Әс-сәламе-галәйкем.

- Мегаләйкем-әс-сәлам.

## Аллаһы һәм кеше

- Мин һәрвакыт диярлек безнең соңгы сөйләшүебез турында уйлыйм, - диде Әхмәт. - Син башта Мәрьям улы Гайсә - Ул кеше, дип әйттең, ә аннары Аллаһы Аңарда Үзен күрсәткән дидең.

Чынлыкта исә кем соң Ул? Мәсих бары Мәрьям улы гына булган вакытта, сез Аннан Аллаһы Улы ясадыгыз, шулай килеп чыга түгелмени?

- Син беләсеңме, Әхмәт, - дип башлады Хәмит, - бу сорауга җавап - монда да һәм мәңгелектә дә, Аллаһы белән мәңгелек тормышка ачкыч. Әгәр без кешене Аллаһ итсәк, бу көферлек *(«ширк»)* булыр иде. Әмма Аллаһы кеше булды, бәлки киресенчә түгел, ди Библия.

Без барыбыз да Мәсихнең кеше кебек тууы белән килешәбез. Пәйгамбәрлекләр буенча Ул - Ибраһим улы, Давыт улы һәм Мәрьям улы. Әмма Мәсих туганчы күп еллар элек алдан әйтелгән пәйгамбәрлекләрдә Аллаһы безгә Үзенең Мәсих йөзендә киләчәген хәбәр итә.

- Син нәрсә, әллә чыннан да Мәсихкә кадәрле рәсүлләр һәм пәйгамбәрләр, Аңарда Аллаһы Үзе ачылачак дип өйрәткәннәр дип әйтергә телисеңме? - дип сорады Әхмәт, гаҗәпләнеп.

- Бар Библиянең төп темасы - ул Мәсих. Шуңа күрә Аллаһының Мәсих турындагы хакыйкатьне инде пәйгамбәрләргә дә ачуына гаҗәпләнергә кирәкми! - диде Хәмит.

- Күрсәт әле миңа, - дип таләп итте Әхмәт. - Мин Язманың бу урыннарын бик күрергә телим.

Хәмит бер минут уйланып торды, аннан соң әйтте:

- Безнең эрага кадәр (ягъни Мәсих Туганга кадәр) якынча 700 ел элек, Аллаһы Михей пәйгамбәр аша Мәсихнең Бәйтлеһем шәһәрендә туачагын ачканда, Ул шулай ук туачакның инде туганга кадәр бик күп элек үк булуын да ачкан.

***«Һәм син, Бәйтлеһем-Ефрафа, Яһүд идарәчеләре арасында һич тә иң кечкенәсе түгелсең. Чөнки Исраилнең Хакиме синнән чыгачак, һәм Аның барлыкка килүе башлангычтан, мәңгелек көннәрдән.» (1)***

Мәсих Бәйтлеһемдә туган. Бу турыда Инжилдә болай язылган:

***«Йосыф та Галилеядәге Насарет шәһәреннән Яһүдиягә, Давыт шәһәренә, Бәйтлеһемгә китте, чөнки Йосыф Давыт нәселеннән иде. Йосыф исемлеккә теркәлергә үзенә ярәшелгән Мәрьям белән бергә барды. Мәрьям авырлы иде. Алар Бәйтлеһемдә булганда Мәрьямнең бала таба вакыты җитте. Мәрьям үзенең беренче баласын – ир баланы тудырды.» (2)***

Дөньяга туганга кадәр бик күп элек үк Булган кем соң Ул? - дигән сорау туа. Ул Үзе Иерусалимда шикләнеп караучы яһүдләр белән сөйләшкәндә болай дигән:

***«Сезнең атагыз Ибраһим Минем көнемне күрәчәгенә шатланды. Ул аны күреп куанды. Яһүдләр Аның бу сүзләренә: Сиңа әле илле яшь тә юк, ә Син Ибраһимны күрдеңме? – диделәр. Гайсә аларга әйтте: сезгә хак сүз әйтәм: Ибраһим булганга кадәр Мин мәңге бар.» (3)***

Без Ибраһимның безнең эрага кадәр (ягъни Мәсих Туганга кадәр) якынча 2000 ел элек яшәгәнен беләбез.

- Димәк, Мәсих Үзенең туганга кадәр булуын раслаган, - диде Әхмәт. - Әмма пәйгамбәрләрнең кайсы урынында Аллаһы Мәсихтә Үзе килер дип язылган?

- Бу Изге Язманың күп урыннарында язылган, - диде Хәмит. - Ишагыйя пәйгамбәр Мәрьям улы Гайсә үскән кечкенә илдән чыгачак Кемдер турында әйткән. Ул, төп сыйфатламасы Аллаһы иминлеге булачак мәңгелек патшалык тудырачак. Ул, шулай ук Давыт улы була-

рак, бу патшалык белән Үзе мәңге идарә итәчәк. Аны атаган төрле исемнәр ярдәме белән, пәйгамбәр Мәсихнең кем булуын тасвирлый:

***«Чөнки безгә сабый бала – Угыл бирелде; Аның исеме: Могъҗиза Иясе, Киңәшче, Кодрәтле Аллаһы, Мәңгелек Атасы, Дөнья Хакиме булачак. Давыт тәхетендә аның патшалыгында Аның хакимлеге вә тынычлык чиксез артачак Ул һәрвакыт һәм мәңге гаделлек вә изгелек белән идарә итәчәк.» (4)***

Без беләбез, Аллаһы кемгәдер биргән шул исемнәр ул кешенең кем булуын тасвирлый. Шулай булгач, Әхмәт, кем соң Ул? Кемне Искиткеч, Киңәшче, Кодрәтле Аллаһы, Мәңгелекнең Атасы, дөньяның Патшасы дип атыйлар?

- Мин Мәсихнең сурәтен гомуми рәвештә, Аның турында әле Ул туганга кадәр үк пәйгамбәрләрдә язылганча, үзләштерә башлыйм кебек тоела, - диде Әхмәт. - Әмма чыннан да сүз Аллаһының Үзе тудырган бу дөньяга киләчәге турында барамы?

- Зәкәрия улы Яхъя Мәсихнең замандашы булган, - диде Хәмит. - Ул Мәсих килгәнгә чаклы, халык аңа тәүбә итә һәм иман китерә алсын өчен, аларны әзерләп куярга Аллаһы тарафыннан җибәрелгән булган. Яхъядан аның кемлеге һәм Аллаһы аны ни өчен җибәргәне турында сораганда, ул җавапка Ишагыйя пәйгамбәрнең 40 сүрәсен-нән өземтә китергән:

***«Чүлдә кычкыручының авазы ишетелә: «Раббыга юл хәзерләгез, Аллаһыбызга сукмакларны турайтыгыз. Һәрбер үзән тутырылсын, һәр тау һәм калкулык тигезләнсен, бормалы-бормалы юллар турайтылсын, сикәлтәлеләре тигезләнеп шомарсын. Һәм Ходайның даны килер, һәм барлык кешеләр Аллаһының коткаруын күрерләр»». (5)***

Ишагыйя тасвирлаганнар бөек патша килүен хәтерлә-тә. Аңа чүл аша яңа, туры, тигез юл төзергә кирәк. Әхмәт, безгә киләчәк бу Патша кем соң Ул?

- Әйе, пәйгамбәрлек буенча бу Раббы, безнең Аллаһы, - диде Әхмәт, уйланып.

- Әгәр без Язманың бу урынын укуны дәвам итсәк, күренеш тагын да ачыгырак аңлашыла төшә, - диде Хәмит. Анда язылган:

***«... Изге хәбәр китерүче Иерусалим, тавышыңны көч белән игълан ит! Курыкма, Яһүднең бар шәһәрләренә әйт: Менә - безнең Аллаһы! Менә халык белән идарә итә торган Раббы Аллаһы Үз куәтендә килә. Ул кешеләргә бүләк алып килә һәм аларга Үзенең савабын бирә. Көтүче үз көтүен көткән кебек, Ходай Үз халкын ияртеп йөртер; бәрәннәрне кулына алыр һәм күтәреп йөрер, аларның аналары да янәшә булыр.» (6)***

Мәсих бар иман итүчеләр өчен чыннан да Көтүче күк килгән. Ул Үзе турында болай дигән:

***«Мин - яхшы Көтүче. Яхшы Көтүче сарыклары өчен гомерен дә кызганмый.» (7)***

- Әхмәт, әмма пәйгамбәр әйтүе буенча Көтүче күк киләчәк, шулай да Кем соң Ул?

- Мин аның Ходай Аллаһының Үзе турында әйтүен танырга тиеш, - диде Әхмәт, пәйгамбәр сүзләреннән соң тирән дулкынланып.

Хәмит дәвам итте:

- Әхмәт, Мәсих турындагы барлык пәйгамбәрлекләрнең Мәрьям улы Гайсәдә тормышка ашуын син мөгаен аңлыйсыңдыр.

Мәсих туар алдыннан Җәбраил фәрештә Яхъяның атасы булачак Зәкәрия янына килгән. Фәрештә Зәкәриягә аның угълы туачагын, һәм бу баланың үзенә бер төрле сәламәте булачагын хәбәр иткән. Җәбраил фәрештә әйткән:

***«(Ул) анасының карынында вакытта ук Изге Рух белән сугарылыр. Ул Исраил балаларының күбесен Раббыга, аларның үз Алласына кире кайтарыр. Ильясныкы кебек рухка һәм кодрәткә ия булып, Ул Раббы алдыннан барыр, аталарны һәм балаларны татулаштырыр, Аллаһыга буйсынмаучыларны тәкъва кешеләрнең фикер йөртү юлына борыр һәм шулай итеп халыкны Раббының килүенә әзерләр» (8)***

- Әхмәт, Инҗил буенча Зәкәрия угълы Яхъя кем алдыннан килгән? Кем соң Ул?

- Аларның Алласы, Ходай, - диде Әхмәт.

- Яхъя тугач та, Зәкәрия үзенең яңа туган угълы турында болай пәйгамбәрлек иткән, - диде Хәмит.

***«һәм син, сабый, Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре дип аталырсың, чөнки Раббыга юлны әзерләп, Аның алдыннан барырсың, һәм Аның халкына гөнаһларынын кичерелүе аркылы булган котылу хакында белдерерсең, Аллаһыбызның шәфкате ташып тора, һәм шуңа күрә безгә югарыдан таң кояшы иңәчәк.» (9)***

Шунлыктан, Яхъя Ишагыйя пәйгамбәр, Җәбраил фәрештә һәм үзенең атасы Зәкәрия сүзләре буенча, Раббыдан алдан килер, ә аның артыннан килүче - бу Аллаһы Үзе.

- Әйе, мин моны аңлыйм, һәм Мәсих килгәннән соң, бу чыннан да дөрес булып чыкты дип уйлыйм, - диде Әхмәт, җитди итеп.

- Әйе, өстәвенә төп-төгәл, - диде Хәмит. - Мәрьям Кыз Давыт шәһәре Бәйтлеһемдә Мәсихне тудыргач, Ходайның фәрештәсе кырдагы берничә көтүчегә күрен-гән, һәм аларга әйткән:

***«Курыкмагыз! Мин сезгә куанычлы хәбәр – бөтен халык өчен зур шатлык алып килдем: бүген Давыт шәһәрендә сезнең өчен Коткаручы туды. Ул - Мәсих Раббы.» (10)***

Мәсих - Ул Ходайның Үзе була дигәне Инҗилдә яңадан расланa. Мәсәлән, Ул болай дип әйткәндә:

***«Мин һәм Ата бер.» (11)***

Мин баштан ук Мәрьям угълы Гайсәне бик нык ярат-тым һәм хөрмәт иттем, - диде Әхмәт. - Әмма мин хәзер беренче тапкыр Мәсихнең чынлыкта кем булуын, һәм Аның дөньяга ни өчен тууын тулысынча күрә алам. Хәмит, вакытыңны кызганмыйча моны аңлатканың өчен мин сиңа чын күңелдән рәхмәт белдерәм.

- Әхмәт, - диде, бик җитди итеп Хәмит, - Мәсихкә иман итүең буенча, Аллаһы сиңа бар гөнаһларыңның акла-нуын һәм мәңгелек тормыш тәкъдим итә.

Үзе үлемне җиңгән һәм үләләрне терелтеп торгызган Мәсих болай дигән:

***«Мин - үледән терелү һәм тереклек. Миңа иман китерүче кеше үлсә дә, яшәячәк. Яшәүче һәм Миңа иман китерүче һәркем һичкайчан үлмәс.» (12)***

Әхмәт, Мәсихкә иман итүең буенча Аллаһы тәкъдим иткән бүләкне кабул итәргә телисеңме?

- Әйе, Ул нәкъ хәзер минем ишегемне шакый дип хис итәм, - диде Әхмәт, күз яшьләре белән.

- Миңа Аллаһының бүләген ничек кабул итәргә?

- Бу авыр түгел, - диде Хәмит. - Үз сүзләрең белән Аллаһыга дога кыл. Аңа барсы турында да тәүбә ит - Аллаһы безнең турында барыбер барысын да белә бит. Синең өчен Мәсих китергән корбан аша аклану кабул ит. Аллаһы Үзенең Рухы белән синең тормышыңа керсен өчен һәм сиңа Мәсихнең өммәте, Аның шәкерте булырлык көч бирсен өчен дога кыл. Бу дога белән Мәсихнең Исеме хакына дога кыл. Ул, Үзенең корбаны аркасында, Алла Ата һәм синең арада Арадашчы булды.

Син Мәсихне шул рәвешчә Аллаһтан бүләк итеп кабул иткәч, синдә бер могҗиза барлыкка килер. Изге Язма син югарыдан туарсың дип өйрәтә. Син Аллаһыдан яңа тормыш һәм Мәсих аша Аллаһы белән яңа шәхси аралашу кабул итәрсең. Инҗилдә Мәсихне кабул итүчеләр турында язылганча, Аллаһы синең Атаң, ә син - Аның угълы булырсың:

***«Ә Аны (Мәсихне) кабул итеп, Аңа иман китерүчеләргә, Ул Аллаһы балалары булырга хокук бирде.» (13)***

Алар дога кылуны тәмам итеп, бергәләп Ходайга рәхмәт белдергәч, Хәмит елмаеп әйтте:

- Безнең гаиләгә рәхим ит! Без хәзер Мәсих аша бөек Аллаһы гаиләсендә кардәшләр.

- Сиңа нинди генә рәхмәтләр белдерим икән! - диде Әхмәт, шатланып.

- Аллаһыга шөкеранә ит, һәм исеңдә тот - моны

һәркөн эшлә, - диде Хәмит. - Үзең кебек үк, Мәсихнең башка өммәтләре белән аралашу эзлә. Менә хәзер син чыннан да, Мәсих Үзенең шәкертләрен өйрәткән кебек, дога кыла аласың:

***«Күктәге Атабыз! Исемең, изге дип, икърар ителсен; Синең Патшалыгың килсен; Күктәге кебек җирдә дә Синең ихтыярың гамәлгә ашсын. Бу көнгә кирәкле икмәгебезне безгә бүген бир. Башкаларның безгә карата эшләгән явызлыкларын без кичергән кебек, безнең да начар эшләребезне Син кичер. Безне сынауга дучар итмә, ә явыздан сакла.» (14)***

# Кушымта

***Изге Язмадан өземтәләр***

Аллаһы Бәрәне
1. Рим. 6:231
2. Ях. 1:29
3. Ачыл. 3:20

Гөнаһ
1. Яшәеш 2:16-17
2. Рим. 5:12
3. Яшәеш 3:15

Аллаһы бирәү генә
1. Ях. 1:1-4
2. Ях. 1:14
3. Лүк. 1:35
4. Ях. 6:33,35
5. Ях. 6:51

Аллаһы Корбаны
1. 1 Тим. 2:5-6
2. Евр. 9:22
3. Иш. 53:4-7
4. Мдх. 21:15-19
5. Марк 10:45

Ибраһим улы
1. Яшәеш 12:1-3
2. Яшәеш 17:19-21
3. Яшәеш 28:13-14
4. Иш. 11:1-2,4,10

Аллаһы һәм кеше
1. Мих. 5:2
2. Лүк. 2:4-7
3. Ях. 8:56-58
4. Иш. 9:6-7
5. Иш. 40:3-5
6. Иш. 40:9-11
7. Ях. 10:11
8. Лүк. 1:15-17
9. Лүк. 1:76-78
10. Лүк. 2:10-11
11. Ях. 10:30
12. Ях. 11:25-26
13. Ях. 1:12
14. Мат.6:9-13

# Эчтәлек

Әхмәт һәм Хәмит ............ 3

Аллаһы Бәрәне ............ 4

Аллаһы Сүзе ............ 8

Аллаһы Корбаны ............ 10

Гөнаһ ............ 14

Ибраһим Улы ............ 18

Аллаһы бирәү генә ............ 22

Аллаһы һәм кеше ............ 28

Кушымта ............ 35

Аллаһының Сүзен күбрәк белергә теләсәгез, Библияне читтән торып өйрәну мәктәбе Сезгә түләусез дәресләр җибәрер. Безнең адрес:
Казан, 420033, а\я - 142, «Иман» мәктәбе.